**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫБАШКАРМА КОМИТЕТ**

# КАРАР

«22» 04 2022 ел Яр Чаллы № 1391

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының «2022-2024 елларга Тукай муниципаль районында наркоманияне профилактикалау» район комплекслы программасын раслау турында» 2022 елның 4 мартындагы 586 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Тукай муниципаль районы халкы арасында наркотиклар кулланун профилактикалау һәм сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау буенча эшне оештыру максатында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр турында» 1998 елның 8 январендагы 3-ФЗ номерлы Федераль закон (үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән), Россия Федерациясе Президентының 2020 елның 23 ноябрендәге 733 номерлы Указы белән расланган 2030 елга кадәр Россия Федерациясенең наркотикларга каршы дәүләт сәясәте стратегиясе, «Наркомания һәм токсикоманияне профилактикалау турында» 2009 елның 29 октябрендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 22 статьясы, «Татарстан Республикасында балаларның сәламәтлегенә, аларның физик, интеллектуаль, психик, рухи һәм әхлакый үсешенә зыян китерүне кисәтү чаралары турында» 2010 елның 14 октябрендәге 71-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2022 елга «2022-2024 елларга Тукай муниципаль районында наркоманияне профилактикалау» район комплекслы программасын гамәлгә ашыру буенча чаралар» бүлеген кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә
2. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.
3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары И.Ш. Бариевка йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллин

«2022 - 2024 елларга Тукай муниципаль районында наркоманияне профилактикалау» район комплексы программасына кушымта

**«2022 - 2024 елларгаТукай муниципаль районында наркоманияне профилактикалау» район комплексы программасын гамәлгә ашыру буенча чаралар**

| № | Чаралар исеме | Финанс чараларын еллар буенча бүлү (сумнарда) | | | Финанслау чыганагы | Башкаручы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2022 | 2023 | 2024 | | |
| 1. | «Здоровый я- здоровая страна!» рәсем конкурсы | 2000 | 2000 | 2000 | «Мәдәният һәм ял үзәге» МБУ | «Мәдәният һәм ял үзәге» МБУ |
| 2. | Тематик әңгәмә: «Мин тормышта сайлыйм», «Басып торам юллар чатында», «Сәламәт булу серләре» | 1500 | 1500 | 1500 | «Мәдәният һәм ял үзәге» МБУ | «Мәдәният һәм ял үзәге» МБУ |
| 3. | «Сәламәт булыйк» рәсем конкурсы | 2000 | 2000 | 2000 | «Мәдәният һәм ял үзәге» МБУ | «Мәдәният һәм ял үзәге» МБУ |
| 4. | «Верь сам в себя наперекор Вселенной!», «Психотропные вещества», «Осторожно человек-помни 21век!» яшүсмерләр өчен нарколог һәм психиатр лекциясе конкурсы | | | | Финанслау таләп ителми | «Мәдәният һәм ял үзәге» МБУ |
| 5. | Яшьләр белән очрашу «Яшьләр һәм наркомания» | 1 500 | 1 500 | 1 500 | «Мәдәният һәм ял үзәге» МБУ | «Мәдәният һәм ял үзәге» МБУ |
| 6. | «Скажи жизни ДА!» түгәрәк өстәл | 3 500 | 3 500 | 3 500 | «Мәдәният һәм ял үзәге» МБУ | «Мәдәният һәм ял үзәге» МБУ |
| 7. | «Правонарушение и ответственность» участковыйлар белән очрашу | | | | Финанслау таләп ителми | «Мәдәният һәм ял үзәге» МБУ |
| 8. | «Үзеңне наркотикларга бәйләмә» чарасы | 1 000 | 1000 | 1000 | «Мәдәният һәм ял үзәге» МБУ | «Мәдәният һәм ял үзәге» МБУ |
| 9. | Түгәрәк өстәл «Минем яшисем килә» | 1 500 | 1 500 | 1 500 | «Мәдәният һәм ял үзәге» МБУ | «Мәдәният һәм ял үзәге» МБУ |
| 10. | Түгәрәк өстәле «Жизнь без наркотиков» | 1 500 | 1 500 | 1 500 | «Мәдәният һәм ял үзәге» МБУ | «Мәдәният һәм ял үзәге» МБУ |
| 11. | Халыкара наркоманиягә каршы көрәш көненә багышланган чаралар оештыру һәм үткәрү | | | | Финанслау таләп ителми | «Мәдәният һәм ял үзәге» МБУ «Мәктәптән тыш |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | эшләр үзәге» МБББУ Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге «Спорт мәктәбе» МБУ «Тукай районы үзәк хастаханәсе» ДАССУ РФ Эчке эшләр министрлыгының Тукай районы буенча бүлеге |
| 12. | «Наркотикам нет!» рәсемнәр, плакатлар конкурсы | 7000 | 7000 | 7000 | «Мәктәптән тыш эшләр үзәге» МБББУ | «Мәктәптән тыш эшләр үзәге» МБББУ |
| 13. | «Надо жить честно!» коррупциягә каршы юнәлешле балалар рәсемнәре һәм плакатлары конкурсы | 7000 | 7000 | 7000 | «Мәктәптән тыш эшләр үзәге» МБББУ | «Мәктәптән тыш эшләр үзәге» МБББУ |
| 14. | «Созвездие Йолдызлык» сәнгать фестивале | 75 000 | 75 000 | 75 000 | «Мәктәптән тыш эшләр үзәге» МБББУ | «Мәктәптән тыш эшләр үзәге» МБББУ |
| 15. | «Без бергә» Республика балалар иҗаты фестивалендә катнашу | 45 000 | 45 000 | 45 000 | «Мәктәптән тыш эшләр үзәге» МБББУ | «Мәктәптән тыш эшләр үзәге» МБББУ |
| 16. | Гомуми белем бирү оешмаларының хокук бозуларны профилактикалау отрядлары арасында конкурс | 6000 | 6000 | 6000 | «Мәктәптән тыш эшләр үзәге» МБББУ | «Мәктәптән тыш эшләр үзәге» МБББУ |
| 17. | «Лучший уголок профилактики по наркомании среди учащихся» конкурсы | 5000 | 5000 | 5000 | «Мәктәптән тыш эшләр үзәге» МБББУ | «Мәктәптән тыш эшләр үзәге» МБББУ |
| 18. | Кыргый үскән наркотиклы үсемлекләр үсү урыннарын һәм бакчачылык җәмгыятьләрендә һәм торак пунктларда аларны законсыз культивацияләүне ачыклау һәм юк итү буенча чаралар | | | | Финанслау таләп ителми | РФ Эчке эшләр министрлыгының Тукай районы буенча бүлеге, авыл җирлекләре башлыклары |
| 19. | Наркотик матдәләр куллануны, җәмәгать урыннарында хәмер эчемлекләрен эчүне булдырмау максаты белән тәүлекнең кичке | | | | Финанслау таләп ителми | РФ Эчке эшләр министрлыгының |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | вакытында яшьләр туплану урыннары буенча уртак профилактик рейдлар | | | | | Тукай районы буенча бүлеге, профилактика субъектлары |
| 20. | Балаларны тәрбияләүдә һәм урнаштыруда практик ярдәм күрсәтү өчен имин булмаган гаиләләргә һәм социаль куркыныч хәлдәге гаиләләргә бару | | | | Финанслау таләп ителми | «Шәфкать» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплексы үзәге, балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе, мәктәпләр |
| 21. | 14 яшьтән 18 яшькә кадәрге балигъ булмаган гражданнарны укудан буш вакытларында эшкә урнаштыру | | | | Финанслау таләп ителми | Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге |
| 22. | Халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенең җәйге каникуллар вакытында балаларны һәм яшүсмерләрне вакытлыча эшкә урнаштыру буенча эше | | | | Финанслау таләп ителми | Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге |
| 23. | «Сообщи, где торгуют смертью» гомумроссия акциясе кысаларында чаралар оештыру | | | | Финанслау таләп ителми | «Мәгариф идарәсе» МКУ, яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге «Мәдәният һәм ял үзәге» МБУ |
| 24. | Спорт ярышларын оештыру һәм уздыру:<br>- Егетләр һәм кызлар арасында бадминтон буенча район беренчелеге һәм чемпионаты,<br>- Яшүсмерләр арасында футбол буенча «Күн туп» район беренчелеге,<br>Авыл җирлекләре, район оешмалары һәм предприятиеләренең ир-ат командалары арасында футбол буенча район чемпионаты,<br>Авыл җирлекләре, предприятиеләр һәм оешмалар командалары арасында волейбол буенча чемпионат | 50000 | 50000 | 50000 | Тукай муниципаль районы «Яшәү урыны буенча яшьләр (яшүсмерләр) клубы» МБУ | Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге |
| 25. | Халыкара сәламәтлек көнен бәйрәм итүгә багышланган чаралар оештыру (7 апрель) | | | | Финанслау таләп ителми | «Мәгариф идарәсе» МКУ, яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | «Мәдәният һәм ял үзәге» МБУ |
| 26. | Бөтендөнья СПИД корбаннарын искә алу көненә багышланган чаралар оештыру | | | | Финанслау таләп ителми | «Мәгариф идарәсе» МКУ, яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге «Мәдәният һәм ял үзәге» МБУ |
| 27. | Бөтендөнья тәмәкесез көнгә багышланган чаралар оештыру (31 май) | | | | Финанслау таләп ителми | «Мәгариф идарәсе» МКУ, яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге «Мәдәният һәм ял үзәге» МБУ |
| 28. | Халыкара наркотикларга һәм аларның законсыз әйләнешенә каршы көрәш көненә багышланган акция | | | | Финанслау таләп ителми | «Мәгариф идарәсе» МКУ, яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге «Мәдәният һәм ял үзәге» МБУ |
| 29. | Тукай муниципаль районы «Спорт мәктәбе» МБУ укучылары арасында спорт ярышлары үткәрү:<br>- егетләр һәм кызлар арасында Бөтенроссия наркотикларга каршы акциягә багышланган йөзү буенча спорт мәктәбе беренчелеге;<br>«Бөтендөнья СПИДка каршы көрәш көне» нә багышланган бадминтон буенча спорт мәктәбе беренчелеге;<br>- чаңгы ярышлары буенча спорт мәктәбе беренчелеге;<br>- кикбоксинг буенча спорт мәктәбе беренчелеге;<br>- егетләр һәм кызлар арасында спорт (ирекле) көрәш буенча спорт мәктәбе беренчелеге;<br>- егетләр арасында көрәш буенча спорт мәктәбе беренчелеге;<br>- Суда бәйрәм: «Весёлые старты!»;<br>- егетләр һәм кызлар арасында өстәл теннисы буенча спорт мәктәбенең ачык беренчелеге;<br>- Гаилә көненә багышланган спорт чарасы; | 43000 | 43000 | 43000 | Тукай муниципаль районы «Спорт мәктәбе» МБУ | Тукай муниципаль районы «Спорт мәктәбе» МБУ |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | - Олимпия көненә багышланган спорт-күңел ачу чарасы | | | | | |
| 30. | Бөтенроссия аеклык көненә багышланган чаралар оештыру (11 сентябрь) | | | | финанслау таләп ителми | «Мәгариф идарәсе» МКУ, яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге «Мәдәният һәм ял үзәге» МБУ |
| 31. | Бөтендөнья СПИДка каршы көрәш көненә багышланган акция үткәрү. | | | | финанслау таләп ителми | «Мәгариф идарәсе» МКУ, яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге «Мәдәният һәм ял үзәге» МБУ |
| 32. | Авыл фельдшерлары арасында «Профилактика наркологических заболевании на селе» темасына семинарлар үткәрү | | | | финанслау таләп ителми | «Тукай районы үзәк хастаханәсе» ДАССУ |
| 33. | «Сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау» темасына профилактика субъектлары белән оештырылган чараларда катнашу | | | | финанслау таләп ителми | «Тукай районы үзәк хастаханәсе» ДАССУ |
| 34. | Наркология кабинетында исәптә торучы авырулар белән дәвалау һәм тернәкләндерү чаралары үткәрү | | | | финанслау таләп ителми | «Тукай районы үзәк хастаханәсе» ДАССУ |
| 35. | Районның һәр торак пунктында "Наркотикларга юк!" дигән темага санитар бюллетеньнәр чыгару, шулай ук күрсәтмә агитация чараларын тарату | | | | финанслау таләп ителми | «Тукай районы үзәк хастаханәсе» ДАССУ |
| 36. | Районның өлкән сыйныф укучылары арасында наркотик матдәләр куллану предметына бәвелгә скриниг тест үткәрү | | 50000 | 50000 | «Мәгариф идарәсе» МКУ | «Тукай районы үзәк хастаханәсе» ДАССУ |
| 37. | Районның гомуми белем бирү оешмаларында наркотикларга каршы профилактик чаралар үткәрү: акцияләр, квестлар, тематик чаралар, мастер-класслар һ.б. | 50000 | | | «Мәгариф идарәсе» МКУ | «Мәгариф идарәсе» МКУ |
| 38. | Асоциаль күренешләрне профилактикалау буенча тәрбия эшләре буенча директор урынбасарлары, педагог-оештыручылар һәм өстәмә белем бирү педагогларының район семинар-киңәшмәләрен оештыру | | | | финанслау таләп ителми | «Мәгариф идарәсе» МКУ |
| 39. | Район үзәк хастаханәсе наркологы, Россия Эчке эшләр министрлыгының Тукай районы буенча бүлеге хезмәткәрләре катнашында гомуми ата-аналар җыелышлары үткәрү | | | | финанслау таләп ителми | «Мәгариф идарәсе» МКУ |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 40. | «SaMoStоятельные дети» наркотикларга каршы проект отрядларының эшен активлаштыру | | | | финанслау таләп ителми | «Мәгариф идарәсе» МКУ |
| 41. | Җәйге сәламәтләндерү кампаниясе чорында тәмәке тарту, алкоголизм, наркоманияне профилактикалау һәм балалар һәм яшьләр белән сәламәт яшәү рәвешен үстерү буенча чаралар оештыру | | | | финанслау таләп ителми | «Мәгариф идарәсе» МКУ<br>Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге |
| 42. | Сәламәт яшәү рәвешен популярлаштыруга һәм психоактив матдәләр куллануны кисәтүгә юнәлдерелгән җәмәгатьчелек фикерен формалаштыру буенча массакүләм мәгълүмат чаралары эшен оештыру. | | | | финанслау таләп ителми | «Якты юл» («Светлый путь») газетасы редакциясе |
| 43. | «Якты юл» («Светлый путь») район газетасы битләрендә халык арасында сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау буенча публикацияләр оештыру | | | | финанслау таләп ителми | «Якты юл» («Светлый путь») газетасы редакциясе |
| 44. | Массакүләм мәгълүмат чараларында наркотикларның законсыз әйләнешенә каршы көрәш һәм наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр куллануны профилактикалау буенча хокук саклау органнары эшчәнлеге турында мәгълүматны яктырту | | | | финанслау таләп ителми | «Якты юл» («Светлый путь») газетасы редакциясе<br>РФ Эчке эшләр министрлыгының Тукай районы буенча бүлеге |
| | **БАРЛЫГЫ:** | **302500** | **302500** | **302500** | | |